**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«07» 08 2025 ел Яр Чаллы ш. № 2634

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны җайга салынучы тарифлар буенча даими йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатында, пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 елның 28 декабрендәге 4575 номерлы карарга үзгәрешләр кертү турында

Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны йөртү белән идарә итү системасын оештыру һәм камилләштерү, Тукай муниципаль районы чикләрендә билгеләнгән транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр формасында грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Тукай муниципаль берәмлеге уставы карары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны җайга салынучы тарифлар буенча даими йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатында, пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Тукай муниципаль районы

Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2023 елның 28 декабрендәге 4575 номерлы карарына әлеге карарга 2 кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә:

1.1. Комиссия составыннан чыгарырга:

- А.Р. Хәбибуллинны;
- Ф.С. Заһретдиновны.

1.2. Комиссия составына кертергә:

- Вәлиуллин Динис Фәнис улын – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары:
- Әмирханова Римма Наил кызын – Тукай муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе.

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълумат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Тукай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2025 елның 07.08. 2634 номерлы карарына 2 кушымта

Комиссия составы
«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны җайга салынучы тарифлар буенча даими йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатында, пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе»

| | |
|---|---|
| Нәҗмиев К.Р. | Комиссия рәисе, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе |
| Вәлиуллин Д.Ф. | Комиссия рәисе урынбасары, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| Мадярова Д.Ә. | Комиссия секретаре, төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге баш белгече |
| Комиссия әгъзалары | |
| Галимова Г.Ә. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең икътисад һәм эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү буенча урынбасары |
| Әмирханова Р.Н. | Тукай муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Исхакова Г.Г. | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы |